# «Каты җисемнәрдә, сыеклыкларда һәм газларда басым» темасына мәсьәләләр чишү

*7 класс*



# Дәреснең максаты:

Өйрәтү максаты: каты җисемнәрдә, сыеклыкларда һәм газларда басым төшенчәсе турында алган белемнәрне системалаштыру, төп терминнарны һәм законнарны кабатлау.

Үстерү максаты: укучыларның мәсьәләләр чишү күнекмәләрен үстерү.

Тәрбия максаты: укучыларда төгәллек, үз фикереңне дөрес итеп аңлата белүне тәрбияләү.

# 1. Үткәннәрне кабатлау.

**1. Басым дип нәрсәне атыйлар?**

Өслеккә перпендикуляр тәэсир итүче көчнең бу өслек мәйданына чагыштырмасына тигез булган зурлык басым дип атала.



**2. Басымны ничек табалар?**

Басымны табу өчен, өслеккә перпендикуляр тәэсир итүче көчне өслек мәйданына бүләргә кирәк.

**3. Сез нинди басым берәмлекләрен беләсез?**

Па, кПа, гПа, мм.тер.баг.

**4. Сыеклыкның савыт стеналарына ясаган басымын нинди формула белән исәплиләр?**

$p = g\rho h$

**5. Паскаль законы ничек әйтелә?**

Сыеклык яки газга ясалган басым сыеклык яки газның һәр ноктасына барлык юнәлешләрдә дә бертөрле күчерелә.

**6. Каты җисемнәрдә басым таяну мәйданын арттырганда яки кимeткәндә ничек үзгәрә?**

Кечерәк басым ясарга теләгәндә таяну мәйданын арттыралар, ә зуррак басым ясарга теләгәндә таяну мәйданын киметәләр.

**7. Ни өчен авыл хуҗалыгы машиналарының тәгәрмәчләрен киң итеп ясыйлар?**

Җиргә ясалган басымны киметү өчен авыл хуҗалыгы машиналарының тәгәрмәчләрен киң итеп ясыйлар.

## 8. Тоташкан савытларда бериш сыеклыкларның өслекләре ничек урнаша?

Теләсә нинди формадагы һәм кисемдәге тоташкан савытлар эчендәге бериш сыеклыкның ачык өслекләре бер үк биеклектә урнаша (сыеклык өслегендәге басым бертигез булганда)



**9. Тоташкан савытларда төрле сыеклыкларның өслекләре ничек урнаша?**

Басымнар тигез булганда, тыгызлыгы зуррак булган сыеклык баганасы тыгызлыгы азрак булган сыеклык баганасыннан кечерәк булыр.



## 2. Әйләнү җисемнәре







Савыт стенасына газның басымы газ молекулалары-ның бәрелүләре нәтиҗә-сендә барлыкка килә.

эйе юк

Таяну мәйданы зуррак булган саен, басым зуррак була.

эйе юк

Басым өслек мәйданына бәйле

эйе юк

Дөрес җавапны сайла һәм әйләнү җисемнәрен җый

# 3. «Ышанасыңмы-ышанмыйсыңмы»

- 1. Басым берәмлеге итеп Н кабул ителгән.
- 2. Басымны p = gρh формуласы белән исәплиләр.
- 3. 1 кПа = 1000 Па.
- 4. Кечерәк басым ясарга теләгәндә, таяну мәйданын киметәләр.
- 5. Кисә,тишә торган коралларны үткен итеп чарлыйлар.
- 6. Нормаль атмосфера басымы 780 мм тер.баг. на тигез.
- 7. Шлюз – тоташкан савыт.
- 8. Уртача һәр 12 м саен басым 1 мм тер. баг. на үзгәрә.
- 9. Атмосфера басымын үлчәү өчен көндәлек тормышта барометр-анероид кулланалар.

Дөрес җавап:




Билге:

5-6 – «3»

7-8 – «4»

9 - «5»

## 4. Тест

1.Кайсы галим атмосфера басымын үлчәү ысулын тәкъдим иткән?

А) Ньютон В) Ломоносов

Б) Паскаль Г) Торричелли

2. Атмосфера басымын нинди хәреф белән тамгалыйлар?

А) F В) p

Б) m Г) S

3. Басымны нинди берәмлектә үлчиләр?

А) кг яки г В) Н яки кН

Б) Па яки мм тер. баг. Г) м/с яки км/сәг

4. Атмосфера басымын үлчәү приборы ничек атала?

А) альтимер В) мензурка

Б) барометр Г) высотомер

5. Нормаль атмосфера басымы күпмегә тигез?

А) 1 Н В) 760 Н

Б) 1 Па Г) 760 мм тер. баг.

6. Авиациядә кулланыла торган биеклек үлчәү приборы ничек атала?

А) высотомер В) анероид

Б) альтимер Г) ареометр

**Тестка җаваплар:**

***Г В Б Б Г А***

**Билгеләр критериясе:**

6 – «5»

5 – «4»

4 – «4»

3 – «3»

2 – «2»

# 5. Мәсьәләләр чишү

№1 Йолдызчык урынына тиешле саннарны язарга:

0,3 гПа = * Па

* кПа = 17000 Па

400 Па = * гПа

970 Па = * кПа

1,2 МПа = * Па

- 0,3 гПа = 30 Па
- 17 кПа = 17000 Па
- 400 Па = 4 гПа
- 970 Па = 0,97 кПа
- 1,2 МПа = 1 200 000 Па

№2 Кеше көрәккә 600 Н көч белән баса. Көрәкнең кисү мәйданы 0,0001 $м^2$ булса, ул җиргә нинди басым ясар?

Бирелгән:

F= 600 Н

S = 0,0001 $м^2$

p -?

Чишү:

p = F : S

p = 600 Н : 0,0001 $м^2$ = 60000000 Па

Җавап: p = 6000 кПа.

№3 Кама елгасында 2 метр тирәнлектә кеше нинди басым кичерә?

Бирелгән:

$h = 2$ м

$\rho = 1000$ кг/м$^3$

$g = 9,8$ Н/кг

p -?

Чишү:

$p = g\rho h$

$p = 9,8$ Н/кг $\cdot$ 1000 кг/м$^3$ $\cdot$ 2 м = 19600 Н = 19,6 кПа.

Җавап: $p = 19,6$ кПа.

№4 Телевизион башня фундаментка, һәркайсының мәйданы 4 $м^2$ булган, 4 таянычка таяна. Башняның массасы 8000 т. Башняның фундаментка ясаган басымын табарга.

| Бирелгән: | СИ | Чишү: |
|---|---|---|
| $n = 4$ | | $p = F : S$ $F = m \cdot g$ |
| $s_1 = 4\ м^2$ | | $S = n \cdot S_1$ |
| $g = 9,8$ Н/кг | | $F = 8000000\ кг \cdot 9,8\ Н/кг = 78400000\ Н$ |
| $m = 8000$ т | 8000000 кг | $S = 4 \cdot 4\ м^2 = 16\ м^2$ |
| $p$ -? | | $p = 78400000\ Н : 16\ м^2 = 4900000\ Па = 4,9\ МПа$ |
| | | Җавап: $p = 4,9$ МПа. |

# 8. Өй эше:

§ 42,43 кабатларга, 19 күнегү №4





# Рефлексия



1.На уроке я работал
2.Своей работой на уроке я
3.Урок для меня показался
4.За урок я
5.Мое настроение
6.Материал урока мне был
7.Домашнее задание мне кажется

актив / пассив
доволе / не доволен
коротким / длинным
не устал / устал
стало лучше / стало хуже
понятен / не понятен
полезен / бесполезен
интересен / скучен
легким / трудным
интересно / не интересно























№4 Метроның Тукай мәйданы тукталышына кергәндә (вестибюльдә) барометр 101,5 кПа.не күрсәтә. Әгәр платформада басым 101674 Па булса, метро нинди тирәнлектә урнашканын билгеләргә.

Бирелгән:

$p_1$ = 101,5 кПа

$p_2$ = 101674 Па

g = 9,8 Н/кг

ρ = 1,29 кг/м$^3$

h -?

Чишү:

$p = g\rho h \quad h = p / g\rho \quad p = p_2 - p_1$

p = 101674 Па – 101500 Па = 174 Па

h = 174 Па / 1,29 кг/м$^3$ · 9,8 Н/кг = 13,76 м

Җавап: h = 13,76 м